| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.12.2019 Казан шәһәре № 11-55/тко

«Торак-коммуналь хуҗалыгы предприятиесе» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлегенең Көнбатыш зонасы буенча төбәк операторы хезмәтенә 2020-2022 елларга чик дәрәҗә бердәм тарифлар билгеләү турында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Торак-коммуналь хуҗалыгы предприятиесе» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлегенең Көнбатыш зонасы буенча төбәк операторы хезмәтенә әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә чик дәрәҗә бердәм тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән чик дәрәҗә бердәм тарифлар 2020 елның 1 гыйнварыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. «Торак-коммуналь хуҗалыгы предприятиесе» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторына ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 21 июнендәге 564 номерлы карары белән расланган Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүмат ачу

стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 19.12.2019 № 11-55/тко карарына кушымта

## «Торак-коммуналь хуҗалыгы предприятиесе» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлегенең Көнбатыш зонасы буенча төбәк операторы хезмәтенә 2020-2022 елларга чик дәрәҗә бердәм тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Татарстан Республикасы территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторы тарафыннан хезмәт күрсәтүгә чик дәрәҗә бердәм тарифлар, сум/куб.м. | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 ел | | 2021 ел | | 2022 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | | | | |
| 1 | «Торак-коммуналь хуҗалык предприятиесе» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | Халык (тарифлар НДС исәпкә алып күрсәтелде)* | 439,03 | 456,60 | 456,60 | 466,36 | 466,36 | 480,85 |
| 1.2 | Бүтән кулланучылар (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 365,86 | 380,50 | 380,50 | 388,63 | 388,63 | 400,71 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясының 6 пунктын тормышка ашыру максатларында аерып чыгарыла

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге